**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Оштырма Юмья авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**«26» май, 2023 ел** **№ 11**

**Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставы нигезендә, Оштырма Юмья авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елның 06 июненә 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Юмья авылы, Үзәк урам, 87 а йорты адресындагы Иске Юмья авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
2. 2023 елның 06 июненә 20 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Юмья авылы, Үзәк урам, 87 а йорты адресындагы Иске Юмья авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

- 2 нче пунктта:

беренче абзацны төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иске Юмья авылында сууткәргеч челтәрләрен һәм су белән тәэмин итү системаларын, артезиан скважинасын, ВНБНЫ ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү, кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч салу, ремонтлау, бетон бораҗлар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);»

түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:

- Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында юлларга вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, сууткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү);

- Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, сууткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Оштырма Юмья авыл җирлеге
башлыгы: С.В. Тимофеев